**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

пр. Ленина, дом 17, с.Актаныш, 423740

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Ленин пр.17йорт, Актаныш ав., 423740

Тел.(85552)3-44-22,факс(85552)3-44-14,E-mail:mail.Aktanish@tatar.ru,www.aktanysh.tatarstan.ru


ПОСТАНОВЛЕНИЕ
30.04.2020

КАРАР
ПР-86

"Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының «Спорт мәктәбе» муниципаль бюджет учреждениесенең "Хезмәткә һәм оборонага әзер" (ГТО) Бөтенроссия физкультура-спорт комплексы сынаулары (тестлары) нормативларын үтәүне бәяләү хокукын бирү турында

" Россия Федерациясендә физик культура һәм спорт турында" 2007 елның 4 декабрендәге 329-ФЗ номерлы Федераль законның 31.2 статьясындагы 3 өлеше нигезендә, "Хезмәткә һәм оборонага әзер" (ГТО) Бөтенроссия физкультура-спорт комплексы нормативларын үтәү буенча халыкка тест үткәрү һәм оештыру максатларында, "Актаныш муниципаль районы" муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты **КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының «Спорт мәктәбе» муниципаль бюджет учреждениесенә "Хезмәткә һәм оборонага әзер" (ГТО) Бөтенроссия физкультура-спорт комплексы сынаулары (тестлары) нормативларын үтәүне бәяләү хокукы бирергә.
2. Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының «Спорт мәктәбе» муниципаль бюджет учреждениесе җитәкчесенә "Хезмәткә һәм оборонага әзер" (ГТО) Бөтенроссия физкультура-спорт комплексының сынау (тест) нормативларын үтәү буенча тест үзәге эшен оештырырга.
3. Актаныш муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы рәисе К.Р.Каюмовага тиешле максатларга каралган бюджет чаралары кысаларында тест үткәрү үзәге эшчәнлеген финанслауны тәэмин итәргә.
4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru/) һәм Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.
5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Л.Ф.Нурлыевага йөкләргә.

Җитәкче И.И.Габдулхаев